СОВЕТ ШЕМЯКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д.63а, с. Шемяк,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422140

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӘМӘК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Г.Тукай ур.,63а нче а йорт, Шәмәк авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422140

тел.(факс): (85563) 2-68-37; e-mail: Shmk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар
22.06.2022ел № 2-17

Шәмәк авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы,«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Уставы,Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмә, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы,Шәмәк авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләр нигезендә,Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Советының 2021 елның 12 ноябрендәге 1-13 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында нигезләмә»не үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыШәмәк авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-7 номерлы карары белән расланган«Мамадыш муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренә аттестация үткәрү турында нигезләмә»не үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Шәмәк авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /И.Н.Зыятдинов/